ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.04.2023 п.г.т.Алексеевское № 126

**Башкарма комитетның 23.09.2013 ел, №735 «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Башкарма комитетның 23.09.2013 ел, № 735 «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» карарына кушымтада (Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 02.11.2015 ел, №451, 11.05.2016 ел, №163, 03.03.2017 ел, №101, 28.12.2017 ел, №471, 26.08.2019 ел, №365, 15.05.2020 ел, №168, 05.02.2021 ел, №32, 30.03.2021 ел, №114 карарларына кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче бүлек. 1.3 нче пункт.Гомуми нигезләмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3 Компенсация алуга хокукны билгеләгәндә гаиләнең җан башына туры килә торган уртача керемен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 03.12.2019 ел, № 1095 «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» карары белән билгеләнгән тәртиптә исәпләп чыгарыла.

- 2.1 пунктының.б пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

б) «түләүне билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме түләүне билгеләү турында гариза бирү аена кадәрге соңгы 12 календарь айда гаилә әгъзаларының керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә;».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазифаларын башкаручы** **М.Р. Гайсин**